Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XXVII-5**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 17 гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны йөкләү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Хәбибуллинның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсендәге 12 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсендәге 9 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 51 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнгәнче Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаруны 2018 елның 17 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Рәшит улы Таҗетдиновка йөкләргә.

2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

3.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов